КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 30 май г.Казань № 757

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елда Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында почта элемтәсе хезмәтләре күрсәтүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында федераль почта элемтәсе оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 10 июль, 539 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елда Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында почта элемтәсе хезмәтләре күрсәтүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында федераль почта элемтәсе оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 10 июль, 539 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 5 август, 568 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2025 елда Татарстан Республикасының авыл торак пунктларында почта элемтәсе хезмәтләре күрсәтүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында федераль почта элемтәсе оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

исемендә «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга;

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга; «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга;

1.6 пунктның икенче абзацында «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга, «2025 елның 30 сентябренә» сүзләрен «2026 елның 31 декабренә» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

7.6 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.4 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «субсидия» сүзен «субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта татар текстында «субсидия» сүзен «субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта татар текстында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга, «субсидияне кире кайтаруны» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтаруны» сүзләренә алмаштырырга, «субсидияне кире кайтару турында» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару турында» сүзләренә алмаштырырга;

8.5 пунктта «субсидияне ирекле рәвештә кире кайтарудан» сүзләрен «субсидия акчасын ирекле рәвештә кире кайтарудан» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин